БАШКАРМА
ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

Татарстан Республикасы

ӘГӘРҖӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНҢ
БАШКОРТМА КОМИТЕТЛАР

Гагарин ур.13, Әгәрже шәһәре, 422230

Гагарин ур., 13 йорт, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-22-46; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

**КАРАР** **КАРАР**

«24» июнь 2019 ел. № 245

Төзелешкә рөхсәт бирү буенча
муниципаль хезмәт күрсәтү
Административ регламентына
үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июленнән 210-ФЗ санлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатыннан, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2010 ел, 2 ноябрь, 880 нче карарына таянып, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты,

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының 14.03.2010 ел, № 85 карары белән расланган төзелешкә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

2.4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Муниципаль хезмәт күрсәтү вакыты, гариза бирү көнен дә кертеп, биш көн".

2.16 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Муниципаль хезмәтләрне электрон формада алу тәртибе турында консультацияне Интернет аша яисә Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр Порталы аша алырга мөмкин.

Әгәр закон нигезендә муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза электрон формада бирү каралган булса, гариза Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр Порталы (http://uslugi. tatar.ru/) яки дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) бердәм порталы (http:/ www.gosuslugi.ru/) аша бирелә.

Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында сервис аша электрон рәвештә хезмәт күрсәтү мөмкинлеге.

2. Әлеге карарны agryz.tatarstan.ru сайтында һәм ТР хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга.

3. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары И.И.Шамсутдиновка йөкләргә.

**Җитәкчесе** **А. С. Авдеев**